Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2019 нчы елның 9 нчы августы 256№

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының җирле үзидарә органнарында коррупция куркынычы белән бәйле Муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген раслау турында

2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында", 2008нче елның 25нче декабрендәге 273-ФЗ номерлы "Коррупциягә каршы тору турында”, 2007 нче елның 2 нче мартындагы 25-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында", 2012 нче елның 3 нче декабрендәге 230-ФЗ номерлы “Дәүләт вазыйфаларын биләүче һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" Федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының 2014 нче елның 23 нче июнендәге 460 номерлы “Керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында" Указы, 2013 нче елның 25 нче июнендәге 50-ТРЗ номерлы "Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы" Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының 2014 нче елның 14 нче ноябрендәге 91 номерлы “Әлки муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Әлки муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау хакында" карары нигезендә, нигезендә Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының җирле үзидарә органнарында коррупция куркынычы белән бәйле Муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген 1нче кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының җирле үзидарә органнарында коррупция куркынычы белән бәйле муниципаль вазыйфалар исемлеген 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының 2017 нче елның 26 нчы апрелендәге 101 номерлы “Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органнарында биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле Муниципаль хезмәт вазыйфалары һәм вазыйфалары

исемлегенә төгәллекләр кертү турында”гы карарын үз көчен югалткан дип таныырга.

4. Әлки муниципаль районы Советының кадрлар эше һәм коррупцион һәм башка хокук бозуларны кисәтү өчен җаваплы оештыру бүлеге начальнигы урынбасарына: Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген һәм коррупция куркынычы белән бәйле муниципаль вазыйфалар исемлеген алып баруны оештырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны коррупциягә каршы тору эшен координацияләү буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль район Башлыгы: А. Ф. Никошин

Совет Алькеевского муниципального района РТ
ИНН 1606004125
ОГРН 1051648018905
2

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Советының 2019 нчы елның 9 нчы августындагы
256 номерлы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органнарында коррупция куркынычы белән бәйле Муниципаль хезмәт вазыйфалары Исемлеге**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. Әлки муниципаль районы Советы аппаратында муниципаль хезмәт вазыйфалары | | | |
| 1 | Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары | Совет аппараты җитәкчесе | 1 вазифа |
| 2 | Муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары | Оештыру бүлеге башлыгы | 1 вазифа |
| 3 | | Юридик бүлек башлыгы | 1 вазифа |
| 4 | | Бухгалтер исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы | 1 вазифа |
| 5 | | Гомуми бүлек башлыгы | 1 вазифа |
| 6 | Муниципаль хезмәтнең башка вазыйфалары | Район башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе | 1 вазифа |
| | | Оештыру бүлеге башлыгы урынбасары (коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат) | 1 вазифа |
| БАРЛЫГЫ | | | 7 |
| 2. Әлки муниципаль районы Башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфалары | | | |
| 7 | Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары | Башкарма комитет җитәкчесе | 1 вазифа |
| 8 | | Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча беренче урынбасары | 1 вазифа |
| 9 | | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 2 вазифа |
| 10 | | Эшләр идарәчесе | 1 вазифа |
| 11 | Муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары | Территориаль үсеш бүлеге башлыгы | 1 вазифа |
| 12 | | Инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы | 1 вазифа |
| 13 | | ГХАТ бүлеге башлыгы | 1 вазифа |
| 14 | | Архив бүлеге башлыгы | 1 вазифа |
| 15 | | Опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы | 1 вазифа |
| 16 | | Авыл җирлегендә яшь гаиләләр һәм яшь белгечләр өчен торак төзелешен субсидияләү программасын үтәү бүлеге башлыгы | 1 вазифа |
| 17 | | Гомуми бүлек башлыгы | 1 вазифа |
| 18 | | Бухгалтер исәбе һәм хисаплылык | 1 вазифа |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | бүлеге башлыгы | |
| 19 | | Яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге башлыгы | 1 вазифа |
| 20 | Муниципаль хезмәтнең башка вазыйфалары | Башкарма комитет җитәкчесенең мобилизация эшләре буенча ярдәмчесе | 1 вазифа |
| 21 | | Территориаль үсеш бүлеге баш белгече | 2 вазифа |
| 22 | | Инфраструктур үсеш бүлеге баш белгече | 1 вазифа |
| 23 | | ГХАТ бүлегенең баш белгече | 1 вазифа |
| 24 | | Опека һәм попечительлек бүлегенең баш белгече | 1 вазифа |
| 25 | | Бухгалтер исәбе һәм хисаплылык бүлегенең баш белгече | 1 вазифа |
| 26 | | Архив бүлегенең әйдәп баручы белгече | 1 вазифа |
| БАРЛЫГЫ | | | 22 |
| 3. Җирле үзидарәнең башка органында, башка җирле үзидарә органы аппаратында муниципаль хезмәт вазыйфалары:<br>а) "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы финанс-бюджет палатасы" МКУдә | | | |
| 27 | Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары | Финанс-бюджет палатасы рәисе | 1 вазифа |
| 28 | | Финанс-бюджет палатасы рәисе урынбасары-бюджет бүлеге башлыгы | 1 вазифа |
| 29 | Муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары | Бухгалтер исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы | 1 вазифа |
| 30 | | Икътисад бүлеге башлыгы | 1 вазифа |
| 31 | Муниципаль хезмәтнең башка вазыйфалары | Бухгалтер исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы урынбасары | 1 вазифа |
| 32 | | Баш белгеч | 1 вазифа |
| БАРЛЫГЫ | | | 6 |
| б) "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы" МКУдә | | | |
| 33 | Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары | Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы рәисе | 1 вазифа |
| 34 | Муниципаль хезмәтнең башка вазыйфалары | Баш белгеч | 2 вазифа |
| БАРЛЫГЫ | | | 3 |
| в) «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Контроль – хисап палатасы " МКУдә | | | |
| 35 | Муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары | Аудитор | 1 вазифа |
| БАРЛЫГЫ | | | 1 |
| 4. Әлки муниципаль районының башка җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфалары | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 36 | Муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары | “Әлки муниципаль районы мәгариф идарәсе" МКУ җитәкчесе | 1 вазифа |
| 37 | | “Әлки район мәдәният бүлеге " МКУ җитәкчесе | 1 вазифа |
| 38 | Муниципаль хезмәтнең башка вазыйфалары | “Әлки муниципаль районы мәгариф идарәсе” МКУ җитәкчесе урынбасары | 1 вазифа |
| БАРЛЫГЫ | | | 3 |
| 5. Әлки муниципаль районы Авыл җирлекләрендә муниципаль хезмәт вазыйфалары | | | |
| 39 | Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары | Башкарма комитет җитәкчесе (Базарлы Матак авыл җирлеге) | 1 вазифа |
| 40 | | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары (Базарлы Матак авыл җирлеге) | 1 вазифа |
| 41 | | (Аппак, Борис, Югары Колчурино, Карга, Кошки, Түбән Әлки, Түбән Әлки, Яңа Үргәагар, Салман, Иске Алпар, Иске Камка, Иске Матак, Иске Салман, Иске Кората, Иске Чаллы, Ташбилге, Чуаш Кичүе, Чуаш Борнае, Чиябаш, Юхмачы авыл җирлекләренең) Башкарма комитеты секретаре | 20 вазифа |
| 42 | Муниципаль хезмәтнең башка вазыйфалары | Советның әйдәп баручы белгече (Базарлы Матак авыл җирлеге) | 1 вазифа |
| БАРЛЫГЫ | | | 23 |
| БАРЛЫК ММИ БУЕНЧА | | | 65 |

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Советының 2019 нчы елның 9 нчы августындагы
256 номерлы карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының җирле үзидарә органнарында биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле муниципаль вазыйфалар Исемлеге**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. Әлки муниципаль районы Советында муниципаль вазыйфалар | | | |
| 1 | Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары | Муниципаль район башлыгы (муниципаль район Советы Рәисе), муниципаль район Советы депутаты | 1 вазифа |
| 2 | | Муниципаль район башлыгы урынбасары (муниципаль район Советы Рәисе урынбасары), муниципаль район Советы депутаты | 1 вазифа |
| БАРЛЫГЫ | | | 2 |
| 2.“Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Контроль-хисап палатасы" МКУдә муниципаль вазыйфалар | | | |
| 3 | Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары | Контроль-хисап палатасы рәисе | 1 вазифа |
| БАРЛЫГЫ | | | 1 |
| 3. Әлки муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарында .муниципаль вазыйфалар | | | |
| 4 | Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары | Авыл җирлеге башлыгы (авыл җирлеге Советы Рәисе), авыл җирлеге Советы депутаты | 20 вазифа |
| БАРЛЫГЫ | | | 20 |
| 4. Әлки муниципаль районы муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органнары башка депутатлары (муниципаль район Советы депутатларыннан һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче авыл җирлекләре Советларыннан тыш) | | | |
| 5 | Депутатлары | Муниципаль район Советының | 40 |
| | | Авыл җирлекләре советлары | 100 |
| БАРЛЫК ММИ БУЕНЧА | | | 162 |